ГЛАВА ЮТАЗИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЮТАЗИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Дмитрова, д.2,
с.Ютаза, 423962

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЮТАЗЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
Дмитров урамы, 2 йорт,
Ютазы авылы, 423962

Тел.:(85593) 4-00-91, факс:4-00-93, e-mail: Utaz.Utz@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
**«26» октябрь 2023 ел** **№ 6**

**2024 елда Ютазы муниципаль районы Ютазы авыл җирлегенең Ютазы торак пунктында гражданнарның үзара салым чараларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында**

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләренә, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсенә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ютазы авыл җирлеге Советының 2019 елның 17 июлендәге 8 санлы карары белән кабул ителгән Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы «Ютазы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 14 маддәсенә ярашлы,

**КАРАР БИРӘМ:**

1.2023 елның 24 ноябрендә 17.00 сәгатькә ТР, Ютазы муниципаль районы, Ютазы авылы, Дмитров урамы, 9 йорт адресы буенча урнашкан авыл мәдәният йорты бинасында 2024 елда Ютазы муниципаль районы Ютазы авыл җирлегенең Ютазы торак пунктында гражданнарның үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены билгеләргә.

2.Гражданнар җыенына чыгарыла торган түбәндәге мәсьәләне расларга:

"Сез 2024 елда Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ютазы авыл җирлегенең Ютазы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, I һәм II төркем инвалидлардан, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүче Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан, Украинада махсус хәрби операциядә катнашучылардан тыш 400 сум күләмендә үзара салым кертергә һәм әлеге акчаларны җирле әһәмияттәге эшләрне башкару өчен тотуга ризамы:

- Ютаза торак пунктында Кыска Елга урамындагы юл-урам челтәрен норматив хәлгә китерү (смета буенча юл төзү: вак таш сатып алу, нигез әзерләү, ташу, салу, проект-смета документациясен әзерләү, килешү буенча эш өчен түләү) ;
- Ютаза торак пунктында Димитров урамындагы юл-урам челтәрен норматив хәлгә китерү(юллар төзү, төзелеш материаллары сатып алу, ташу, вак ташлау, асфальтлау, килешү буенча эш өчен түләү);
- Ютаза торак пунктында Ленин урамындагы юл-урам челтәрен норматив хәлгә китерү(ясалма тигезселек урнаштыру;смета нигезендә асфальт сатып алу,алып кайту,салу,проект-смета документлары ясау,килешу нигезендэ эшлэр өчен түләү );
- Ютаза торак пунктын төзекләндерү (коры, кипкән агачларны, куакларны кисү, территорияләрне җыештыру, килешү буенча эш өчен түләү);
- Урам яктыртуларын ремонтлау (материаллар сатып алу, килешү буенча эш өчен түләү);

- Ютаза торак пунктында зират территориясендәге коймаларны ремонтлау (төзелеш материаллары сатып алу, килешү буенча эш өчен түләү) ;

- Ютаза торак пунктында торак пункт эчендәге юлларны карап тоту (юлларны кардан чистарту, килешү буенча эш өчен түләү)

«РИЗА» «КАРШЫ»

3. Ютазы авыл җирлеге башкарма комитетына гражданнар җыенын оештыру һәм үткәрүне йөкләргә.

4. Әлеге карарны Ютазы муниципаль районы Ютазы авыл җирлегенең мәгълүмати стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru, һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә веб-адрес буенча урнаштырырга: http://jutaza.tatarstan.ru.

5. Әлеге карар рәсми рәвештә игълан ителгәннән соң үз көченә керә.

Ютазы авыл җирлеге башлыгы




Л.М.Хәйруллина